РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы, ул. Пионерская, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл жирлеге
Башлыгы

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы, Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.karmalinskoe-sp.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 29 мае № 4

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә һәм гражданнардан кергән мерәҗәгатьләргә анализ ясауның бердәм тәртибен билгеләү максатларында, йөклим:

1. Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибән расларга (кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Д.Кубышкин

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге башлыгының
2020 елның 29 мае
4 номерлы карары белән расланган
кушымта

Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мерәҗәгатьләренә анализ ясау
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мерәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге Советына, Башлыгына, Башкарма комитетына кергән гражданнар мерәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели (алга таба – җирле үзидарә органнары).

2. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формаларын һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Кергән мерәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау елга 1 тапкыр башкарыла.

4. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан хисап чорында җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау турында хисап (алга таба - Хисап) рәсмиләштерелә.

5. Хисап үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, яңадан адресланган һәм каралган язма мерәҗәгатьләр, электрон документ формасында кергән мерәҗәгатьләр саны турында мәгълүмат;

- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;

- шәхси кабул итүдә кабул ителгәнгражданнар саны турында;

- гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;

- мөрәҗәгатьләр тематикасы турында;

- мерәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шулисәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат (булганда).

6. Тиешле вакыт эчендә җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ, шул исәптән узган елның шул УК чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы беләндә уздырыла.

7. Хисап вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштырыла.